ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№390 от «08» 12 2021 г.

«2020-2022 елларга Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районында Физик культура һәм
спортны үстерү» муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

«2016-2020 елларга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасы, «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 163 нче карары белән расланган «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына ( 13.11.2020 ел, 396 нчы, 12.03.2021 ел, 100 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасының Паспортындагы «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә. (1 нче кушымта).

- 2020-2022 елларга Мамадыш муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү буенча чаралар турында:

- 5 нче санлы «Матди- техник базаны үстерү» бүлегенә 5.10. һәм 5.11 пунктчаларын өстәргә. (2 нче Кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.12.2021 ел,
№390 санлы карарына
1 нче кушымта

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау Мамадыш муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, билгеләнгән тәртиптә җирле бюджетка бүлеп бирелгән күләмдә республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылачак:<br>2020 ел - 64 830,1 мең сум.<br>2021 ел - 68 753,5 мең сум.<br>2022 ел - 69 527,9 мең сум.<br>шул исәптән республика бюджеты:<br>2020 ел- 210,1 мең сум (спорт инвентаре)<br>2021 ел- 231,5 мең сум (спорт инвентаре)<br>2022 ел- 214,5 мең сум (спорт инвентаре)<br>2021 ел – 346,9 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга)<br>2021ел – 100,0 мең сум (яңа ачылган спорт объектларына спорт инвентаре алу өчен)<br>2021 ел – 176,4 мең сум (спорт объектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алу өчен. |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.12.2021 ел,
№ 390 санлы карарына
2 нче кушымта

**5. . Матди-техник базаны үстерү**

| № | Чараларның эчтәлеге | Үтәү вакыты | Үтәлеш өчен җаваплы | Финанслау күләме (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 | 2021 | 2022 |
| 5.10 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә спорт объектларының терроризмга каршы якланыуын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өлешендә (республика бюджеты). | 2021-2022 еллар | «Хоккей һәм физик культура буенча спорт мәктәбе» МБУ, «СШ «Олимп» МБУ, «Стадион-ипподром» МБУ, крытый плавательный бассейн «Лагуна» ябык йөзү бассейны | - | 176,4 | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.11 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә, бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыруга, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга, спорт объектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә (җирле бюджет). | 2021-2022 еллар | «Хоккей һәм физик культура буенча спорт мәктәбе» МБУ, «СШ «Олимп» МБУ, «Стадион-ипподром» МБУ, крытый плавательный бассейн «Лагуна» ябык йөзү бассейны | - | 1,8 | - |